# АКТАНЫШ ТАҢНАРЫ

*М. Ногман сүзләре*

**Moderato cantabile**




лә-рен-дә.
Ак-та-ныш
таң-на-ры,
ул ми-нем йө - рәк се-рем - не
1.
аң - лар -
мы?
2. Кабатлау өчен
аң - лар - мы?
2. Тәмамлау өчен.
аң - лар - мы?

Акчарлаклар очып уйный
Актаныш күлләрендә.
Ул гына яши елмаеп
Күңелем түрләрендә.

К у ш ы м т а:

Актаныш таңнары,
Ул минем йөрәк серемне
аңлармы?

Зәңгәр кичтә Агыйделгә
Йолдызлар коела сыман.
Аны гына сайлап алдым
Бик күпләр арасыннан.

К у ш ы м т а.

Очып кына китәр идем
Актаныш якларына.
Өзгәләнгән минутым бар
Юксынган чакларымда.

К у ш ы м т а:

Актаныш таңнары,
Ул минем йөрәк серемне
аңлармы?